I

*Дөнья базарында халкымның тик*
*Ялтырыйдыр алтын-көмешләре.*
*Ә мин йөрим милләт бакчасында*
*Татып аның ачы җимешләрен...*



## КҮЗГӘ КҮРЕНМӘГӘН НОКТА

Имәнепләр багам, алда мине
Әллә нәрсә, белмим, көтә кебек.
Бик ерак та сыман, якын да ул —
Серле Нокта...
жанны өтә кебек.

Шушы Нокта мине торган саен
Ымсындырып тарта үзенә гел.
Үзем куркам, үзем атлыйм һаман —
Әллә нигә жаным тыныч түгел.

Ничек исән калгандыр ул Нокта?
Ничек кенә кибеп сулмагандыр?
Жаннар кыеп йөргән адәмнәргә
Ничекләр ул мишень булмагандыр?

Әллә минем карашларым гына
Барып житәме соң ул Ноктага?
Юкса бәхет көлмәгән дә киеп
Тумадым бит фани бу дөньяга.

Барыбер мин барып житәрмен көк
Ул Ноктага, иртәдерме, соңмы.
Жанны телгәләгән серле Нокта
Жанкаемнан көчкән изге чыңмы?..

...Тик булмасын иде соңлап кына
Тапкан Ноктам гомеремнең соңы...

## ТУГАН ТЕЛЕМ

Туган телем —
күк җанына ашкан,
Мәгърур таулар теле син.
Үз хокукын хаклап яулар чапкан
Изге даулар теле син.

Үксез далаларда өнсез калган
Чал балбаллар теле син.
Утлар-сулар кичеп исән калган
Ак бабамнар теле син.

Сүнәм дигәндә дә сүрелмәгән
Изге ялкын теле син.
Шанлы дәверләрнең шаһы булган
Газиз халкым теле син.

Гарешләрдән дога булып иңгән
Адәм, Һава теле син.
Җанга, канга иман булып сеңгән
Шифа, дәва теле син.
И туган телем!..

* * *

Ятлар салган юлдан бармадым мин,
Юлсыз юлдан һәрчак атладым.
Күкләремә багып, эчтән генә
Һаман изге сүрә ятладым.

Адашканда, тимерказык йолдыз
Юл күрсәтте миңа төннәрен.
Юлдаш булды бары тулган Аем,
Читләткәндә хәтта тиңнәрем.

Ялгыз бүре кебек уладым мин,
Өмет йолдызыма юл тотып.
Ач булсам да, ятлар өлешенә
Ташланмадым.
Һәрчак ут йотып
Дәвам иттем изге юлымны мин,
Сүрелсә дә рухым, көчләрем.
Нинди гаҗәп: һәрчак өннәремдә
Юш килделәр минем төшләрем.

Җан дусларга түгел, ак кәгазьгә
Серләремне чишеп бушандым.
Булды инде, булды... Кайчакларда
Ала каргага да ышандым.

Булды инде... Ант-вәгъдәләр биреп,
Торалмаган чаклар сүземдә.
Үтергәнче кытыклаган чаклар
Шүрәленең хәтта үзен дә.

«Иблис коткысы»на бирелеп тә,
Үз кыйбламны ләкин җуймадым.
Язмадым мин юлдан, кирәк чакта
Тормыш сәхнәсендә уйнадым.

Нигә читләтергә? Барыбыз да
Коябыз ла бер үк инешкә.
Ә сез, барсагыз да шома юлдан,
Соңарырсыз кебек финишка...

## ТУКАЙ КАРАШЫ

Ул карашта... ил җанына сыенып,
Төннәр буе күзге җилләр елый.
Ул карашта... зеңләп тартылган күк
Бер мөкатдәс моңлы сазның кылы.

Рәнҗү, кайтмаган үч...
                    ул карашта
Төбәлгәнме әллә утлы уктай?
Карашыннан яраланган дошман —
Дуэльләргә чакырмаган Тукай.

Кырыс хакыйкате заманнарның,
Намус, вөҗдан, тормыш чынлыгы да —
Гомер буе яшен булып яши
Карашларның серле тынлыгында.